**СОВЕТ АЛЬДЕРМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422711, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Альдермыш, ул. Хабибуллина, 25

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЛДЕРМЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422711, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Әлдермеш авылы, Хабибуллина урамы, 25

тел./факс 8(84365) 79-4-03, e-mail: Alder.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**30 сентябрь 2020 ел** **№ 9**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланып куелган вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» Әлдермеш авыл җирлеге Советының 2018 ел 30 апрель 104 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы», Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» карары һәм Әлдермеш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Советының 30.04.2018 ел, 9 номерлы карары белән расланган «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларның хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" (Советның 2018 елның 30 апрель, 104 номерлы, 2018 елның 13 декабрь 140 номерлы карары редакциясендә), Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата түләү күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга.

2. Әлдермеш авыл җирлеге Советының 30.04.2018 елда кабул ителгән 104 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карары (Советның 2018 елның 30 апрель,

104 номерлы, 2018 елның 13 декабрь  140 номерлы карары редакциясендә) белән билгеләнгән тәртиптә Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен 2020 елның 1 октябреннән арттырырга.

3. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен, әлеге карарның 2 пункты нигезендә, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләмен 1,03 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11498 күләмендә билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Советының 2018 елның 30 апрелендәге 104 номерлы "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" карары белән расланган 2 нче кушымтаны (Советның 2018 елның 30апрель, 104 номерлы, 2018 елның 13 декабрь  140 номерлы карары редакциясендә), таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге башлыгының акчалата түләү күләме"

| Вазыйфаның атамасы | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | 12 группа |
| Авыл җирлеге башлыгы | 15759 |

5. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Әлдермеш авыл җирлеге бюджетында тиешле финанс елына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Биектау муниципаль районы рәсми сайтында  http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/  авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Т.С.Сабиров